# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**13 ноябрь 2024 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 7 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләрдә көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , хәрби хезмәт үтү турында контракт төзеп һәм махсус хәрби операциягә җибәрелде, 2 төркем инвалидларга бер тапкыр бирелә торган түләүне 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм алыштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистартканда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү, трактор йөртүченең үләнне механикалаштырып чаптыру буенча хезмәтләре өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82(чапкыч) өчен асмалы җайланмалар сатып алу, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу)?»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 297 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 166.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 166, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

« Сез Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләрдә көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , хәрби хезмәт үтү турында контракт төзеп һәм махсус хәрби операциягә җибәрелде, 2 төркем инвалидларга бер тапкыр бирелә торган түләүне 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм алыштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистартканда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү, трактор йөртүченең үләнне механикалаштырып чаптыру буенча хезмәтләре өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82(чапкыч) өчен асмалы җайланмалар сатып алу, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу?».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче, И.М.Камалетдинов
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы